СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның июленнән бирле чыга. | №36 (7209) | 28 март, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

Семинар-киңәшмә

26 мартта районның колхоз һәм совхоз, промышленность предприятиеләре, оешмалары, учреждение җитәкчеләре, җаваплы партия һәм совет работниклары, авыл хуҗалыгы идарәсе белгечләре катнашында семинар-киңәшмә булып үтте.

Киңәшмә районның XXI партсъезд исемендәге колхозында башланып китте. Аны кереш сүз белән район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов ачты. Кунаклар хуҗалыкның реконструкцияләнгән терлекчелек биналарын, андагы җиһазлар һәм терлек азыгы әзерләү машиналарын карадылар.

Киңәшмәнең икенче өлеше «Комбайн» колхозында дәвам итте. Биредә семинарда катнашучыларны савым сыерларын асрау технологиясе, азык әзерләү ысуллары белән таныштырдылар. Кунаклар катнаш азык заводында булдылар.

Семинарда катнашучылар язгы чәчүдә катнашачак авыл хуҗалыгы машиналарын карадылар. Аларны ремонтлау, көйләү, регулировкалау һәм агротехник таләпләр буенча рекомендацияләр тыңланды. Быелгы язгы чәчүне кыска срокта һәм югары сыйфатлы итеп үткәрү буенча бурычлар турында КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков, авыл хуҗалыгы идарәсе баш агрономы Н. М. Мусин, баш инженеры М. В. Зәйнуллин һәм башка белгечләр чыгышлар ясадылар.

Киңәшмәгә йомгакны район Советы председателе КПСС райкомының беренче секретаре Х.Х.Морадыймов ясады. Ул үзенең чыгышында быелгы елның үзенчәлекләренә тукталды. Шуңа да ул быел язгы чәчүгә хәзерлек бер елда да булмаганча гаять зур җаваплылык таләп итүен ассызыклады. Аннан хуҗалык җитәкчеләре, белгечләре, авыл халкы, төрле җәмәгать оешмалары алдында торган конкрет бурычларга тукталды.

Константин яшьтән үк тимер-томыр белән мәш килеп үсте. Үскәч тә туган авылы кырларын эшкәртү, иген үстерү өчен механизатор һөнәрен сайлады. Армия хезмәтенә кадәр дә, аннан соң да җанытәне белән эшкә алынды.

Узган ел тракторчы, аннан соң силос җыю комбайнында комбайнчы булып эшләде. Әгәр башкаларга үрнәк булмаса механизаторлар алдында абруй казаныр идемени. Быел үзен комплекслы трактор бригадасы бригадиры итеп сайлап куюлары нәкъ шул хакта сөйли дә. Хәзерге вакытта Константин бар көчен техниканы язгы кыр эшләренә хәзерләүгә бирә.

Әйе, халык язмышы, аның киләчәген хәл итәсе җаваплы эшләр тора аның алдында.

Рәсемдә: «Знамя Октября» колхозы механизаторы Константин Кудряшов.

Мактаулы исем

Халык мәгарифе өлкәсендәге хезмәтләре өчен Октябрь районының 1 нче номерлы Норлат урта мәктәбе укытучысы Николай Лаврентьевич МАКЕЕВка Татарстан ССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә «Татарстан ССРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

Һәрсә ни хак?

Шуны белергә теләгән укучыларыбыз редакциягә шалтырата башладылар. Бардыр дип «Аргументы и факты» газетасындагы мәгълүматларны сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Кызыксынучылар тагын да (Бу исемлек тулы түгел).

	Элекке ваклап сату бәяләре	Яңа ваклап сату бәяләре
Сыер ите—1 категория	2-00	7-00
Сарык ите—1 категория	1-90	6-00
Дуңгыз ите—II категория	1-90	5-30
Эче алынган тавык ите	3-40	5-60
Аертылмаган сөт	0-28	0-50
Атланмай	3-50	8-80
Каты сырлар	3-20	6-40
Майлы эремчек	1-00	2-00
Диетик йомырка	1-30	2-60
Туң балык (алабуга)	1-01	2-40
Югары сортлы бодай оны	0-46	1-40
Карабодай ярмасы	0-56	1-68
Дөге	0-88	2-20
Тары	0-30	1-00
Шикәр комы	0-85	2-00
Көнбагыш мае	1-70	3-40
Маргарин	1-50	3-00
Чәй (кг)	9-60	18-00
Батон	0-33	1-00
ПРОМЫШЛЕННОСТЬ ТОВАРЛАРЫ		
Ситсы	1-12	3-00
Паплин	2-00	4-20
Костюмлык тукыма	12-80	30-00
Мәктәп формасы өчен тукыма	8-00	33-00
Шакмаклы одеял (140х205 см)	17-00	54-00
Ирләр майкасы	1-34	4-70
Хатын-кыз оеклары	0-70	3-00
Йон җептән ирләр бәйләм күлмәге	34-00	78-00
Ярым йон тукымадан ирләр костюмы	107-00	245-00
Озын җиңле ирләр күлмәге	8-60	16-50
Ситсыдан тегелгән хатын-кызлар күлмәге	11-30	26-00
Хатын-кызлар өчен полиуретан табанлы туфлиләр	18-00	24-50
Йон җептән балалар бәйләм күлмәге (36 нчы үлчәм)	12-50	59-00
Балалар өчен гади җептән колготкилар	1-60	4-50
38 нче үлчәмле мәктәп формасы (кызлар өчен)	12-00	62-00
Малайлар өчен туфлиләр	8-50	21-50
Эшкәртелмәгән сарык тиресеннән пальто (28 нче үлчәм)	46-00	175-00
Туры җөй тегә торган тегү машинасы	67-00	125-00
Мәктәп дәфтәрләре	0-02	0-10
Балалар чаңгылары	4-20	15-50
Диван-кровать	188-00	346-00
«Лотос» кер юу порошогы, 1 кг.	1-00	1-60
«Саратов» маркалы суыткыч	250-00	430-00
СМР-1,5 маркалы кер юу машинасы	80-00	165-00
«Рубин» маркалы төсле телевизор	755	1218-00
«Рекорд» маркалы аклы-каралы телевизор	240-00	440-00
«Океан» маркалы радиоалгыч	135-00	207-00

Компенсация ничек түләнә?

Базар экономикасына күчү уңаеннан товарларга һәм хезмәт күрсәтүгә бәяләрнең күтәрелүе хезмәт ияләрен иң борчыган сорау бүген. Бу уңайдан районда бәяләрнең күтәрелүен компенсацияләү буенча махсус комиссия төзелгәнлеге газетада хәбәр ителгән иде инде. Бүген бу комиссия члены район финанс бүлеге мөдире Р. Г. БИЛАЛОВ компенсация түләү тәртибе һәм суммасы белән таныштыра:

—Билгеле булганча, 1991 елның 19 мартында СССР Министрлар кабинеты «Ваклап сату бәяләренә реформа һәм халыкны социаль яклау турында» карар кабул итте.

Азык-төлек һәм промышленность товарларына күтәрелә торган бәяләрне каплау максатында агымдагы елның 20 мартыннан бәяләр күтәрелүдән алда акчалата компенсация түли башлауны кертте. Ул түбәндәге тәртиптә үткәрелә:

—барлык төр предприятиеләр эшчеләренә, хезмәткәрләренә, колхозчыларга, эшләүче пенсионерларга компенсация күләме—айга 60 сум;

—эшләмәүче пенсионерларга—65 сум;

Апрель аеннан балалары булган гаиләләргә социаль пособиеләрнең хәрәкәттәге күләмнәре шулай арттырыла:

—һәр бала туган саен бер мартәбә 250 сум пособие бирелә;

—бер еллык эш стажы булган, 18 яше тулмаган һәм производстводан аерылып укучы аналарга баласы яшь ярымга җиткәнче 110 сум күләмендә;

—90 сум күләмендә айлык пособие 6 дан 18 яшькәчә балалары булган ялгыз аналарга;

—6 дан 18 яшькәчә балаларга әти-әнисе алимент түләүдән читләшкән очракта;

—80 сум күләмендә айлык пособие еллык эш стажы булмаган һәм эшләмәүче хатын-кызларга баласы яшь ярымга җиткәнче караган өчен;

—уртача айлык керем һәр гаилә членына 280 сумнан ким булган очракта яшь ярымнан 6 яшькәчә булган балаларга түләнә.

Моннан тыш социаль страхование һәм социаль тәэмин итү исәбенә пособие һәм пенсия алмаучы балаларга ай саен түләү 16 яшькә кадәр 40 сум күләмендә һәм 18 яшькәчә стипендия алмаучы укучы балаларга түләнә.

Балалар товарлары ассортименты кыйммәтләнү уңаеннан балигъ булмаган балалары бар гаиләләргә компенсацион түләүләр түбәндәге күләмдә кертелә:

—6 яшькәчә балалар өчен кимендә 50 сум;

—6 дан 13 яшькәчә балалар өчен кимендә 60 сум;

—13 яшьтән 18 яшькәчә балалар өчен кварталга кимендә 70 сум түләнә.

Алда билгеләп үтелгән компенсация түләүләр һәр гаилә членына акча кеременең гомуми суммасы 280 сумнан артмаган очракта үткәрелә.

Тиешле пособиеләр һәм компенсацияләрне түләү бер үк вакытта үткәрелә. Кимендә 10 айдан аз булмаган вакыт укучы барлык **төр** профессиональ-техник **уку** йортларында укучы**ларга** компенсация рәве**шендә** айга 40 сум күлә**мендә** стипендия бирелә.

«Халыкның эшкә тартылуы турында» республикалар һәм СССР Законының 28 статьясы нигезендә эшсезлек буенча пособие алучылар айга 50 сум күләмендә компенсация алырга хокуклылар.

Гражданнар компенсация түләү мәсьәләләре белән төп эш урыннарына, эшләмәүче пенсионерлар исә социаль тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать итәргә тиешләр.

Җәйге вакытка күчмибез

СССР Бердәм вакыт һәм эталон ешлыклар дәүләт комиссиясе 31 мартта җәйге вакыт башланачагын хәбәр итте. Әмма без җәйге вакытка күчмибез. Быел сәгать угын күчермәүче республикалар, крайлар һәм өлкәләр арасында ТАТАРСТАН ССР да бар.

Игътибар: туры элемтә

Балигъ булмаганнарның хулиганлык, җинаять эшләүләре турында хәбәрләр әледән-әле килеп тора. Бу өлкәдә эшне яхшырту максатында Октябрь районы эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эше буенча инспекциясе халык фикерен өйрәнү өчен районда яшәүчеләр белән туры элемтә үткәрергә дигән фикергә килде. Туры элемтә район Советы башкарма комитеты каршындагы комиссия членнары,прокуратура,РОНО һәм район газетасы редакциясе хезмәткәрләре катнашында барачак. Кисәтүләрегез, киңәшләрегез, сорауларыгызны эчке эшләр бүлегенә яки «Дуслык» газетасы редакциясенә җибәрә аласыз.

Ә «Туры элемтә» 30 нчы март, шимбә көнне иртәнге сәгать 9 дан 12гә кадәр барачак. 2—15—64 номерлы телефон буенча шалтыратуыгыз сорала.

Газетабызның 2—3 битләре «Чирмешән» колхозының бүгенгесе, киләчәге һәм аның уңган эшчәннәренә багышланган.

ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ

БЕЗНЕҢ «Чирмешән» колхозы әле үткән елның апрель аенда гына оешкан иде. Инде бәләкәй генә булса да йомгак ясап карасак та була. Бер ел эчендә без нәрсәләр майтара алдык соң?

Башлап шунысын әйтеп үтәсем килә. Колхозыбыз өч авылны: Кәкре Атау, Иске Авыл һәм Кара Күлне берләштерә. Барлык җиребез 2353 гектар булып, сөрүлекле җирләр исә 1486 гектар тәшкил итә. Шунысын да әйтергә кирәк, хуҗалык табигатьнең матур бер кочагына сыенган, яныбыздан гына шагыйрьләргә илһам бирүче Чирмешән елгасы ага, әллә ничә чакрымнарга сузылган тирәп, мул сулы күлебез бар. Әнә шулар тугайларында 461 гектар көтүлек һәм печән җирләребез бар. Шушы җирләрне эшкәртү, мул продукция алуда бүгенге көндә 215 алтын куллы хезмәт кешеләребез бар.

1990 ел безнең өчен зур сынау елы булды. Без нәрсәләр эшли алабыз, нәрсәгә сәләтле икәнлегебезне үзебез алдында да, ил алдында да исбат итәргә тиеш идек. Бу яктан колхозчыларыбызга рәхмәтем чиксез зур. Үткән елда бөртеклеләр һәм бөртекле-кузаклыларны 642 гектарда чәчкән идек, шулардан уртача 22 центнер уңыш алдык. Аерым алганда 246 гектар арыш һәр гектарыннан 25,4 центнер, 90 гектар борчак уртача 23,1 центнер, 100 гектар язгы бодай 21,1 центнер уңыш бирде. Шуның нәтиҗәсендә бөртеклеләрнең, бөртекле-кузаклыларның тулаем уңышы 14136 центнер тәшкил итте. Шикәр һәм азык чөгендереннән 20300 центнер уңыш алдык.

Дәүләт амбарларына 3050 центнер ашлык озаттык.

Игенчелек белән берлектә колхозда икенче тармак —терлекчелек уңышлы гына старт алды. Хуҗалыкта барлык мөгезле эре терлекнең 240 башы савым сыер исәпләнә. Җәй айларында гына сарыкчылык белән шөгыльләнә башладык. Хәзерге көндә 868 баш сарык исәпләнә. Бу тармак әле яңа, күп нәрсәләргә өйрәнәсебез бар. Әмма товарлыклы-сөтчелек фермасы әйбәт нәтиҗәләр күрсәтеп эшләп килә. Әйтеп киткәнемчә 240 баш савым сыерга 17 савучы беркетелгән. Бу тату сөтчелек комплексы план нигезендә 5675 центнер урынына 0616 центнер сөт сатып дәүләт заказын уңышлы үтәп чыкты.

Биредә мин ел әйләнәсендә һәр сыердан уртача 4 мең чигең узып китеп сөт савып алган терлекчеләребез турында горурланып искә алам. Үз группасындагы һәр сыердан уртача 4588 килограмм сөт савып Нурдидә Алиева фермабыз маягы булды. Фәүзия Мөхетдинова 4427 килограмм, Исламия Гөлметдинова 4300, Миңнегөл Сафиуллина 4114, Гамбәр Ахунҗанова 4082, Зәйнелгарәп Гыйләҗева 4040 килограмм сөт савып алдылар. Бу хезмәтчәннәр безнең горурлыгыбыз, мактанычыбыз. Шунысы да куанычлы, савучы булып егетләребез дә эшли хәзер бездә. Илшат Хәсәнҗанов менә 3 ел инде матур күрсәткечләр белән эшләп килә. Үткән ел да ул үз группасыннан уртача 3457 килограмм сөт савып алды.

Әйе, ирешелгән уңышларыбыз өчен иң беренче чиратта кешеләргә бурычлы. Шуңа күрә алны-ялны, көнне-төнне белмичә тиешле йөкне үз урынына илтеп җиткерү өчен бөтен тырышлыгын биргән шоферларыбыз турында җылы сүзләр әйтәсе килә. Безнең Әсхәт Гыйләҗев 32190 тонна-километр, Дамир Хәлиуллин 30226 тонна-километр юл үтеп йөкләмәләрен үтәделәр. Алар кебек үк тырыш Рәшит Гыйләҗев, Әхтәм Хәсәнҗанов, Наил Шәйдуллиннар үз хезмәтләренә намус белән карыйлар, машиналары төзек, көйле, үзләре колхозны тернәкләндерү өчен бөтен көчләрен куялар.

Басуларны эшкәртү, уңыш алу өчен техника паркыбыз елдан-ел тулылана. 22 тракторыбыз, унга якын комбайныбыз бар. Биредә тәҗрибәле механизаторлар кыр эшләренең бөтен төрендә дә сынатмаска тырышалар. Вахит Сабиров, Рияз Гыйләҗев, Мәҗидулла Габидуллин, Юныс Фәтхетдинов, Рифкать Гыйләҗев, Азат Вәлиәхмәтовлар чын мәгънәсендәге кыр батырлары.

Хуҗалыкны техника белән тулыландыруга аеруча игътибар итәргә тырышабыз. Чөнки без табигатьнең матур җирендә яшәсәк тә, аның бит көйсезлекләре дә әле үзен сиздерә. Күп вакыт куәтле техникага сусыйбыз, шуңа күрә үткән елда К-700, чылбырлы Т-150, кукуруз урдыру өчен КСК-100, ДТ-75 тракторлары сатып алдык, аларның тагылма җайланмалары да юнәлтелде.

Ирешелгәннәр чик түгел. Бу әле безнең беренче адымнарыбыз. Алда күп проблемалар тора, басуларның уңдырышлылыгын күтәрү, һәр сыердан савылган сөтне 4 мең чигеннән үткәреп җибәрү, ныклы азык базасы булдыру, төзекләндерү эшләре турында күп уйланасы, күп эшлисе бар. Ә боларны бары кадрлар гына хәл итә, башка урыннардагы кебек бездә дә бу кыен мәсьәлә. Ниндидер җаен табарга, уйланырга, эзләнергә, халыкның үзе белән киңәшне даими өзмичә хәл итәсе төп мәсьәлә бу. Ә халык әйбәт безнең, минемчә, болар киләчәктә уңай хәл ителер.

Ж. РӘХИМОВ,
колхоз рәисе.

Бүгенге Кәкре Атау авылы мәчетенә 100 яшь бар. Аның үткән тарихы кызыклы. Алпавыт Илья Федорович Сазонов үзенең кап суга торган амбарын элекке мәчет янгач авыл картларына бүләк итеп бирә. Аны мәчет итеп күтәрәләр. Бу мәчеттә Һади Кәлимуллин, Нуриҗан Исмәгыйлев, Сәмигулла Галиев, Мәхмүт Гатауллин имам, ә Нәбиулла Шәйдуллин мулла булып торганнар. Дингә каршы кискен көрәш алып барылган чорда да гореф-гадәтләр, йолалар саклана килгән.

Кәкре Атауда бүгенге көндә мулла булып 82 яшьлек карт Солтангали Галәветдинов тора. Авыл картлары мәчеткә иртән намазга, сәгать уникедә өйләгә, сәгать дүртенче яртыда икенде, биш-ун минутлар торганнан соң ахшам, янә ун минуттан ясигъ укырга киләләр.

Мәчет динне генә пропагандалап калмый, мәрхәмәткә, шәфкатьлелеккә, бары яхшыга гына өйрәтә. Амин, шулай булсын. Бездән соң килгән буын сафлансын, нурлансын, элек дәвам иткән гүзәл традицияләр онытылмасын.

Авыл алга карап яши

Моннан унбиш-егерме ел элек чыгып киткән кеше, басу капкасын кергәч, үз авылын танымый тора. Аның алдында матур күренешләр ачыла. Еш кына шуны күзәткәнем бар, шәһәрчә матур киенгән кунаклар (хәер авыл кешеләре дә алардан калышмый хәзер) урамнарга сокланып кат-кат әйләнәләр.

Авылларда салам түбәләр, җимерек йортлар беткәнгә биш былтыр инде. Төз булып сузылган урамнарда балкып яңа йортлар утыра. Безнең колхозда гына да соңгы ун ел эчендә икешәр квартиралы 16 йорт төзелеп унган колхозчыларга тапшырылды. Үз көчләре белән нигез яңартучылар турында әйтәсе дә юк. Колхоз биредә булдыра алган ярдәмен кызганмый. Ике ел элек зур, матур кибет төзелеп файдалануга тапшырылды. Биредә өч бүлек: хуҗалык, ашамлык һәм кием-салым бүлекләре бар. Үткән ел гына матур культура йортыбыз үзенең тантанасына авылдашларны җыйды. Яшьләребез беренче концертлары белән күрше авылларга да чыгып керделәр инде. Сызлансаң, рәхим ит, сине өр-яңа медицина пункты көтә.

Колхоз төзелеше дә көннән-көн колач ала. Үткән ел сарык фермасы үзгәртеп корылды, ашлык саклау бинасы яңартылды. Ындыр табагына асфальт җәелеп, яңа чистарту җайланмалары кайтартылды. 40 тонна исәбеннән автоүлчәгеч сафка керде.

Болар билгеле уңышларыбыз, ә эшләнәсе, кирәкле объектлар күп әле. Быел минераль ашламалар өчен склад төзү, механизаторларга бик кирәк гараж төзү күздә тотыла. Өч авылга да такта яру җайланмалары урнаштыру да исәптә тора.

Бу эшләр, бу үзгәрешләр кешеләрнең фикерен дә үзгәртә, авылга, колхозга яңача карарга мәҗбүр итә. Быел җиде егетебез армиядән кайткан иде, шуларның бишесе туган авылында калды.

Балалар бакчасы булдыру турында да эшлекле сөйләшүләр башлап җибәрдек. Чөнки бу безнең бик авырткан мәсьәлә, күп яшь гаиләләр эшкә чыга алмый интегә. Җыеп кына әйткәндә, бу проблемаларны чишүдә безгә югарыдагы тиешле оешмалар да эшлекле ярдәмен күрсәтми калмас.

М. КЫЯМОВ.

Елмайсын аналар

Ана да, балалар да елмая икән, димәк бу гаилә бәхетле дигән сүз. Ә гаилә бәхете өчен яраткан хезмәтен булу, янында тәгәрәшеп йөргән балаларың, һәртөрле җил-давылларда да иренең нык җилкәсен тою булса, шул җиткән. Хәер, кайберәүләр аны чүпрәк җыюдан, дефицит нәрсәләр табудан күрәләр. Мин исә Зәйнәп Фәсхетдинованы беренче төркемгә кертер идем. Менә егерме ел инде ул үзе сайлаган һөнәренә тугрылыклы булып кала килә. Колхозның уңган терлекчеләренең берсе. Үткән елда да ул үзенә беркетелгән һәр сыердан уртача 3610 килограмм сөт савып алган, шулай итеп халык кулланышына бер Зәйнәптән генә дә 55122 килограмм сөт озатылган.

Янында тәгәрәшеп йөрүче балалары да бишәү, Наил, Наилә, Фаил, Фаилә мәктәптә укыйлар, ә бәләкәй Рәмзис өйдә әле. Балаларның өлкәннәре кул арасына күптән керә башладылар. Ишле гаиләнең мәшәкате дә ишле була, һәркемгә эш табыла. Бу яктан балалар авыр эшләрне дә үз җилкәләренә алырга тырышалар. Әниләрне беләсез инде, балаларын кызгана. Ә аларда күмәк эш авырлыкны сиздерми. Ире Әсхәт, ул колхозда ветфельдшер, Зәйнәпнең киңәшчесе дә, таянычы да, нык сүзле гаилә башлыгы да. Бер сүз белән әйткәндә, Зәйнәп тормышыннан канәгать. Бәләкәйләрен канат астына җыеп елмаеп утыра ул.

Рәсемдә: кызы Фаилә, улы Рәмзис белән З. Фәсхетдинова.

Саннар һәм фактлар

Яңа башка чыккан «Чирмешән» колхозының 2353 гектар җире бар. Шуның 1486 гектары сөрү җире. Тагын 461 гектар табигый болынлыклары һәм печәнлекләре җәелеп ята.

x x x

Колхозда 215 хезмәт кешесе исәпләнә.

x x x

Хуҗалык былтыр бөртекле һәм бөртекле-кузаклылардан 22 центнер уңыш җыеп алды. Бөртеклеләрнең тулай җыемы 14136 центнер тәшкил итте. Шикәр һәм азык чөгендереннән 20300 центнер уңыш җыелды.

x x x

Техника паркында 22 трактор, 10 комбайн һәм башка техника, тагылма инвентарь бар.

x x x

Терлекчелектә дә күркәм уңышлары бар хуҗалыкның. Узган ел савым сыерлардан сөт алуда яхшы нәтиҗәгә —һәр сыердан 4 мең килограммнан артык сөт савуга ирешкән алдынгылар туды. Колхоз былтыр дәүләткә 6016 центнер сөт сатты.

Хезмәтебез дә, яшәвебез дә бергә

Үзең турында сөйләү бик кыен инде ул. Ә менә Нурдидә турында бик рәхәтләнеп, бәйнә-бәйнә сөйләп була. Без бер үк елларда мәктәптә сигезенче классны тәмамлау белән фермага килдек. Хәзер шактый зур тәҗрибәбез бар, чөнки 20 ел аз гомер түгел. Терлекчелекнең күп серләренә, күп нечкәлекләренә төшендек. Нурдидә үз группасындагы һәр сыердан уртача 4588 килограмм, ә мин 4040 килограмм сөт савып алдык. Бераз гына көнләшәм дә инде, шул ук вакытта шатланам да. Туганым бит ул минем. Фаҗигале төстә вафат булган ирем Тәлгать аның туган абыйсы иде. Мин ике бала белән тол калдым. Шулай да ялгызлыкны бик сиздермәс өчен Нурдидә дә, ире Вахит та бөтенесен эшләргә торалар. Өйдә дә, фермада да өчебез дә гел бергә диярлек. Чөнки без колхоз салган бер үк йортның ике канатында яшибез. Вахит та фермада эшләгәнгә күрә хезмәт урыныбыз да бергә. Эшебезне яратабыз. Аннары үзебезне дә хөрмәт итәләр. Әле быел савымчыларга стаж өчен дә түләү булды. Мин 520 сум, Нурдидә 254 сум өстәмә хезмәт хакы алдык. Айлык хезмәт хакы да 250, 300 сум була. Эшебезгә җаваплы карауның бәясе бу. Гаиләләребезнең татулыгы балаларыбыз арасында да дәвам итә. Минем икәү, алардан өчәү мәктәпкә бергә чыгып китәләр, кайткач та гел бергә. Әнә шулай яшибез. Җитәкчеләребезнең дә, халыкның да җылысын тоеп яшәгәнгә әле алда тагын да матуррак эшләрбез дип әйтер идем.

З. ГЫЙЛӘҖЕВА.

Рәсемнәрдә: Н. Алиева һәм З. Гыйләҗева.

Кече авыл проблемасы

Яшәгән җирдән тәм табыйк

Кышкы чана юлы. Ап-ак кар дөньясына карыйсың да, тирә-юньдәге сихри матурлыкка кабат хәйран каласың. Нинди сафлык, пакълык!

Бу җирләрдә кайчандыр каеннар шаулаган. Борынгы бабаларыбыз болгарлар каеннар шавы кешегә кайгы-хәсрәт китерә дигәннәр һәм үзләре урнашкан авылны бөтенләйгә дип ташлап киткәннәр. Шуннан инде, вакытлар үтү белән иске авыл урынына яңа буын кешеләр күчеп килгәннәр. Иске Авылның исеме дә шулай туган.

Ничек кенә булмасын, каеннар күп булган җирдә йорт салсаң, кайгы-хәсрәт килә яки бәхетсез буласың дигән сүзләр дөреслеккә охшый. Ничәмә-ничә еллар үткән, ә шул җирдә иген иккән, тир түккән крестьян үзен әле хәзер дә бәхетле дип саный алмый. Ни өченме? Әйдәгез, бу авыл кешеләре белән якыннанрак танышыйк.

Пенсия яшендәге Зәйнәп Галиуллина яшь чакта урман кисү, урак уру, печән чабу, көлтә бәйләү, үгез җигеп сабан сөрү, җир казу, сыерлар җигеп элеваторга ашлык ташу кебек эшләргә йөргән. Нурлаттан үзенең туган авылына башкалар белән беррәттән орлыгын да күтәреп ташыган. Ашаган ашы—бәрәңге уып ясалган ипи. Кигән киеме—киндер ыштан, чабата (ул да булса тишек), әллә ничә җирдән ямаулы бишмәт. Шундый авыр заманнарда да үз кәефләрен күтәрә белгәннәр. Кызлар аулак өйгә җыелганнар, туйганчы биегәннәр. Ә бит якты Ильич лампасы урынына керосин уты янып торган, тамакны ялгарга өйдәгеләрдән яшерә-яшерә соңгы бәрәңгеләрен алып килгәннәр. (Анысын да әле малай-шалай урлый).

Зәйнәп апа менә шуларны уйлый да, үз авылының пенсионер картлары һәм карчыкларына карата булган битарафлыкны күреп әйтер сүз тапмый. Күп тә түгел бит инде югыйсә үзләре. Хет утының китереп бирсеннәр иде. Бер ярты булмаса, бәрәңге чәчәр өчен җирләрен дә сөрдерә алмыйча иза чигәләр.

Авыл кибетен инде бөтенләйгә ябарга җыенганнар иде, бәхетләренә Равил Кәлимуллин сатучы булып керергә ризалашты. Ни әйтсәң дә акча кирәк, өч малаен өйләндерәсе бар. Керүен керде дә, тик ни белән сәүдә итә? Биләр Озеро ХРТПсыннан берни дә бирмиләр. Авыл халкы январь аенда бер мәртәбә 400 грамм токмач, аннан соң тары ярмасы алган. Ә калган продуктларны күргәннәре дә юк. Иске Авылда нибарысы бер Бөек Ватан сугышы ветераны бар. Тик фронтовик та үзенә тиешле льготалардан файдаланмый, аңа берни дә бирелми. Кайчандыр, яшь чагында, безнең иминлекне саклап дошман өстенә бөркеттәй ташланган кыю совет солдатын онытмасыннар иде, ичмасам...

Иске Авылда мәктәпне бар дип тә, юк дип тә әйтеп булмый. Биредә нибары бер укучы бала бар. Аның исеме Алсу. Беренче класста укый. Ничек укуын эти-әниләре: Наилә һәм Рифкать Габбасовлар сөйли.

—Кызыбызны Кәкре Атау авылыннан Наилә Шәйдуллина килеп укыта,—диләр алар.—Х класс белеме бар. Үзе хәзерге вакытта укып йөри. Мәләкәстә бухгалтерлар курсында белем ала. Наилә сессиягә киткәннән бирле кызыбызның менә 1 ай була инде укыганы юк. Әллә район халык мәгарифе бүлегенә барыргамы дип торабыз.

Алсу укый торган бүлмәне Габбасовлар үзләре ягарга мәҗбүр. Габбасовларның тагын ике уллары бар: Рәфис белән Рәмзис. Рәфис сигезенче класста, Рәмзис алтынчы класста укыйлар. Көн саен иртән Иске Авылдан 5—6 километр ераклыктагы Биләр Озеро урта мәктәбенә юл тоталар. Җәяү йөрүче бу укучы балаларда беркемнең дә эше юк.

—Әле менә,—ди әниләре Наилә, —кичә мәктәпкә бара алмыйча кире борылып кайттылар. Юл юк. Төштән соң тагын кузгалдылар, юлга таяклардан билге салып кайттылар.

Юлның булмавы бу яклар өчен зур проблема инде. Кәкре Атауга ярый әле маршрут автобусы йөри башлады дип сөенергә юк. Ул Иске Авыл, Кара Күл кебек кече авылларга йөрми. Әле Кәкре Атауга да теләсә килә, теләмәсә юк. Бикүле авылы шоферы үз дәрәҗәсен күрсәтә. «Чирмешән» колхозының үз шоферы булса, болай кыланыр идеме икән соң?

Шунысы гаҗәпләндерә, Биләр Озеро кебек унъеллык мәктәптә интернат булмасын инде. Балаларга шундый шартлар да тудыра алмаган колхозга укытканчы, «Чирмешән» колхозы аларны үзләре туып үскән Кәкре Атауда укытса, кулай булыр иде. Кара Күлдән Биләр Озерога укырга йөрүче тагын ун укучы бала да шулай иза чигәләр икән.

—Быел көзен бөтен дөньяны су басты,—дип сүзгә кушыла Рифкать.—Балалар укырга йөри алмадылар, шуның өчен педагоглар безне гаепли.

Габбасовлар авылда иң яшь кешеләрдән саналалар. «Чирмешән» колхозы булып яши башлаганнан бирле Иске Авыл кешеләренә эш беткән. Элек хет кирпеч заводында хезмәт куйсалар, хәзер анысы да эшләми. Авылда яшьләр калмый дип зарланырга нигез бар. Колхоз квартиралар салуда ярдәм итсә, эш булса, яшьләр арасында авылда калырга теләк белдерүчеләр дә бар. Дөрестән дә, җитәкче иптәшләр аз гына булса да башларын кашысалар, моның юлларын эзләп табарлар иде. Әйтик, теләүчеләргә колхоздан симертү өчен бозауларны нигә тапшырмаска? Берәр ферма төзелсә дә комачаулык итмәс иде. Кеше бит үзе яшәгән җирдән генә түгел, башлап эшләгән эшеннән ләззәт таба.

Иске Авылның үз медпункты да, кирәк чакта шалтырату өчен телефоны да юк. Берәр төрле бәлаказа булса ходай язмасын

(Башы. Ахыры 4 биттә).

Игенче язга хәзерләнә

Чабыш аты сабантуйны бөтен йөрәге белән сиземләп ашкынып көткән кебек игенче дә язны бөтен күңеле белән көтә, аңа җентекле хәзерлек алып бара. Бу җәһәттән хуҗалык эшчәннәре язгы чәчүгә кирәкле тагылма җайланмаларны ремонтлауга аеруча әһәмият бирергә тырышалар. Мөстәкыйль икенче язга аяк басканда бу бигрәк тә үзен нык сиздерә.

Колхозда булган тагылма инвентарьлардан тырмалар, чәчкечләр, культиваторлар барысы да ремонтланып беткәннәр. Хәзер аларны кайсы басуга нинди күләмдә куллану буенча комплектлау бара. Тракторларны да җентекләп карау, ремонтлау эше тәгәлләнеп килә инде.

Ремонтлау өчен тәҗрибәле осталардан аерым бригада төзелде. Биредә слесарьлар Сәлимгәрәй Хәйруллин, Рияз Сафиуллин, Ралиф Шәйдуллин, тимерчеләр Җәмил Фәсхетдинов, Әхәт Нуруллин, токарь Хәмзә Шакиров үзләренең тәҗрибәләрен дә, осталыкларын да кызганмадылар. Бу эш белән җитәкчелек итүче Рияз Мотыйгуллин кирәкле детальләрне табарга тырышты, ремонттан үзе дә читтә калмады.

Билгеле яз өстәмә мәшәкатьләр дә тудырыр. План нигезендә алда әйтелгән ремонт бригадасы һәр механизаторга кыен очракта ярдәмгә чыгарга әзерләнә. Колхоз идарәсенең планында туклану, ягулык белән тәэмин итү, кырга орлык чыгару кебек бик әһәмиятле мәсьәләләр дә чагыла, аларга җаваплы кешеләр бүгеннән үк билгеләнә инде.

В. АБДУЛЛИН.

Тәрәзәсе көнгә бага

Кәкре Атау авылында тәрәзәләрен көньякка багып бик матур бер өй тора. Шәйдуллиннар йорты ул. Әле өлгертеп керүләренә дә ике генә ел. Аны Әхмәтсәлим абый үз көче белән өлгерткән. Колхозда кирпечтән салынган йортлар да елдан-ел арта. Ә менә Әхмәтсәлим абыйның көче бар чагында тагын бер йорт өлгертәсе, хуш исе аңкыта торган агач өй саласы килгән. Бу уңган куллы абыйның белмәгән һөнәре юк. Төзүче булып озак еллар эшләгәннән соң, тимерчелеккә килә, быел менә матур гына 60 яшьлек бәйрәмен дә үткәреп куя. Үзе ясаган тәрәзә рамнары, сырлап эшләгән ниргәләр останың тәм табып, яратып эшләвен әйтеп торалар. Хәер мондый матурлыкны күп кешегә өләшкән ул. Шуңа күрә авылдашлары аның турында сөйләгәндә эчке бер җылылык белән: «Кулларыннан бәхет тапты, күп игелек эшләде, картлыгының да бәхетен татып яшәсен!»—диләр.



27 март—Халыкара театр көнә

ЛЕНИНГРАД. Владислав Игнатьевич Стржельчик —М. Горький исемендәге Академия Зур драма театры артисты.

Социалистик Хезмәт Герое, РСФСРның Дәүләт премиясе лауреаты, СССРның халык артисты, Россия театр эшчәнлеге союзының Ленинград бүлеге идарәсе рәисе. Бу исемлектә—артистка чын күңелдән бирелгәнлек, аны ихтирам итү, җаваплылык.

Күптән түгел В. И. Стржельчикка 70 яшь тулды. Ярты гасырга якын иҗади хезмәт, югары сәнгатькә булган фидакарь хезмәт артта калды.

Рәсемдә: Н. Саймонның «Бу чиксез сөю» комедиясеннән күренеш. Элейн Наваццо ролен А. Б. Фрейндлих, Барни Кэшменны В. И. Стржельчик уйный.

(ТАСС фотохроникасы).

Яшәгән җирдән тәм табыйк

(Ахыры. Башы 3 биттә).

инде!) транспорт эзләп күрше авылларга йөгерәчәкләр. Клуб хакында аерым сүз кузгатырга кирәк. Эче, тышы известь белән агартылган бу бинаны авылда кызыл почмак дип йөртәләр. Кайчандыр авыл халкы бирегә кино карарга булса да йөрсә, инде хәзер ансыннан да мәхрүм. Концерт-театрларны исә күргәннәре дә юк. Дөрес, бер мәртәбә Кәкре Атау клубы үзешчәннәре килеп бик матур спектакль куеп киткәннәр. «Яшел эшләпә» дип исемләнгән ул спектакльне авыл халкы әле дә яратып сөйли: «Рәхмәт төшсен клуб мөдире Мөнир Хәлиуллинга», дип зур рәхмәт укыйлар. Кече авылларны үзешчәннәр онытмасыннар иде шул. Авыл халкы өчен кечкенә генә программа да зур бәйрәм бит. Тик менә әлеге кызыл почмакның куркыныч ягы да бар икән. Тикшерү белән килгән янгын сүндерүчеләр үргән чыбыктан янгын чыгу ихтималы барлыгына кисәтү ясаганнар. Әмма шулай булса да бу авазга ни өчендер Кәкре Атау электриклары колак салмый. Электр турында сүз кузгалгач, бер урамлы кечкенә генә авылда баганалардагы лампочкаларның янмавын да әйтеп үтү урынлы булыр иде. Иске Авылда су проблемасы да хәл ителмәгән. Һаман да кое суы эчәләр. Әле анысы да җәй буена булмаган. Урам коесы апрель аенда ишелгән. Иске Авылга су башнясы кайтарсалар да, аны, кирпеч заводын да күздә тотып Гәйтән ягына куйганнар. Аның да суы юк.

Менә шулай көн итә Иске Авыл халкы. Алда әйтелгән мәсьәләләр хәл ителмәгәндә тагын ун елдан авылның нигезе калмаячак. Гүзәл табигатьле авылга, аның яхшы күңелле кешеләренә ярдәм кулы сузарга кирәк.

Г. РӘХИМОВА.

ЯШҮСМЕР НИЧЕК ЯШИ?

Соңгы елларда безнең республикада эчке эшләр бүлегенең эшчәнлегендә балигъ булмаганнар арасындагы җинаятьчелекне бетерү көн кадагындагы проблемаларның берсенә әйләнде. Безнең район да шуннан читтә калмады. Яшүсмерләр арасында җинаятьчелек үсмәсә дә, хокук бозу күренешләре кала бирә. Әйтик, 1990 елда район эчке эшләр бүлегенең дежур частена һәм балигъ булмаганнар инспекциясенә 195 яшүсмер китерелде. Шулардан 46 сы вак хулиганлык кылган өчен, 40 сы—спиртлы эчемлекләр кулланучылар, 109 яшүсмер—башка төрле хокук бозучылар. Күпчелекне укучы яшьләр тәшкил итә.

1991 елның ике аенда районда балигъ булмаганнар тарафыннан ике җинаять эшләнде һәм 29 яшүсмер милициягә китерелде.

Тагын бер мөһим борчулы сигнал бар: башлыча җәй көннәре һәм сентябрь урталарына кадәр шәһәр урамнарында, танцы мәйданында яшьләр арасында бәрелешләр булып тора. Ә быел алар бүгенге көнгәчә дәвам итә, әле ахыры да күренми. Ул гына түгел, бу сугышларда кече яшьтәге укучылар саны арттаннан-арта бара.

1990 елда группа сугышларында катнашкан өчен 34, ә 1991 елда өч яшүсмер административ җаваплылыкка тартылдылар.

Җинаятьләрнең күбесе беркая эшләмәүче һәм укымаучы балигъ булмаганнар тарафыннан эшләнә. 1990 елда шундыйлар 45 әү булса, бу ел башыннан 10га җитте. Әлбәттә, болар милиция кулына эләгүчеләр генә әле.

Районда чыгарылыш класс укучыларын яки бөтенләй укымаучыларны эшкә урнаштыру системасы булмавы, яшүсмерләр арасындагы җинаятьчелекне кискенләштерә генә. Предприятие, оешма җитәкчеләре хуҗалык исәбе белән эшләүгә сылтап, яшүсмерләрне эшкә алудан баш тарталар, хәтта район Советы башкарма комитеты каршында эшләп килүче балигъ булмаганнар эше буенча комиссия карарларын да санга сукмыйлар.

Үткән елларда хокук бозу очраклары авылларда һәм шәһәрдә тигезләшә иде. Ә узган елда шәһәрдә яшәүчеләр бу өлкәдә ике тапкыр, кайбер хокук бозуларда өчәр тапкыр да артып киттеләр. Бу мәгълүматлар шәһәр яшүсмерләренең шөгыльсезлектән, буш вакытын файдалы итеп уздыра белмәүдән җинаятьчелек юлына басулары турында тагын бер кат дәлилли.

Т. ГЫЙРФАНОВ,
балигъ булмаганнар инспекциясенең өлкән инспекторы.

Телевидение

ШИМБӘ
30 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

16.50 Нәфис фильм: «Этиләр». 2 серия.
17.55 «Юл куркынычсызлыгы». Кинопрограмма.
18.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
18.25 Реклама.
18.30 Документаль телефильм премьерасы: «Гримсыз».
19.00 Татарстан.
19.30 «Җырлыйсым килеп тора». Зәй автоагрегат заводының «Ләйсән» вокаль ансамбле коллективы белән очрашу (4 март тапшыруын кабатлау).
20.00 Тыныч йокы, нәниләр.
20.15 Әлли-бәлли-бәү.
20.25 Александр Васильевның хор өчен язылган әсәрләрен Чувашия ССРның дәүләт радиосы хоры башкара.

I ПРОГРАММА

6.30 Кырым татарларының халык җырларын С. Мәмәтова башкара.
6.50 Мультфильмнар.
7.15 Спорт һәркем өчен.
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
8.30 Безнең бакча.
9.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
9.15 «Шигърият минутлары». А. Хабаров.
9.25 Әкиятләр һәм маҗаралар дөньясында. Нәфис фильм: «Алтын каз».
10.40 «Бурда моден» тәкъдим итә...
11.10 Таң йолдызы.
12.10 А. Н. Островский. «Яшенле яңгыр» фильм-спектакле.
15.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Сәяси диалоглар: «Кем ул кем».
16.45 «Талантлар һәм аларга баш иючеләр». Балалар өчен музыкаль программа.
17.40 Халыкара панорама...
18.25 Нәфис телефильм премьерасы: «Теманың балачагы».
21.00 Вакыт.
21.45 «Алтын диск-90». Вячеслав Добрынинның иҗат кичәсе.
23.45 Телевизион яңалыклар хезмәте.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильмнар.
8.45 Тхеквондо. СССР—Испания очрашуы.
9.15 Рус теле.
9.45 Документаль фильм: «Көн озынлыгы».
10.00 Хезмәттәшлек видеоканалы.
12.15 РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында.
13.30 «Унберне кушкач» видеоканалы. (14.15—РСФСР халык депутатларының чираттан тыш съездында).

ЯКШӘМБЕ
31 МАРТ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 «Сәхнә утлары». ТССРның халык артисткасы Н. Гәрәева бенефисы. (Тапшыру кабатлап бирелә).
18.40 «Халык иҗатының III Бөтенсоюз фестивале». Азнакай районы үзешчән сәнгатьтә катнашучылар чыгышы.
19.50 Әлли-бәлли-бәү.
20.00 Азнакай районы үзешчән сәнгатьтә катнашучылар концертының дәвамы.
20.55 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

8.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
8.15 Ритмлы гимнастика.
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 Иртән иртүк.
10.00 Ватанга хезмәттә.
11.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
11.30 Хайваннар дөньясында.
13.00 Авыл сәгате.
14.00 Мультфильм.
14.00 Сез моңы булдыра аласыз.
15.00 Телевизион яңалыклар хезмәте.
15.15 Сәламәтлек.
15.45 «Яңа буын сайлый». «Шанс».
17.15 Өч кылда соло.
18.10 Уолт Дисней күрсәтә.
19.00 «Мәхәббәтне уйлап тапкан адәмгә дан». Лирик концерт.
19.30 Режиссер С. Самсонов фильмнары.
21.00 Вакыт.
21.45 КВН-91.
23.45 Футбол күзәтү.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильм: «Яланаяк һәм аның дуслары».
8.35 М. Кугель уйный (Альт).
9.05 Лама Данзане турында уйланулар.
9.30 Чишмәләр.
10.00 Балалар өчен фильм: «Денис Кораблевның гаҗәеп маҗаралары». 1 һәм 2 сериялэр.
12.10 «Унберне кушкач» видеоканалы.
15.40 Документаль фильм премьерасы: «Камкага реквием».
16.20 Мария Биешу җырлый.
21.45 Авторлык телевидениесе.

СОРАУ—СЕЗДӘН, ҖАВАП—БЕЗДӘН

Минем ирем Гәрәй Миннехан улы Шәфиков 1 группа сугыш инвалиды иде. Ул 1971 елда үлде. Миңа хәзер 63 яшь. Колхоз пенсиясе алам. Ялгызым яшим. Ирем вафат булганлыктан, аның пенсиясе миңа күчерелмиме икән? Нинди дә булса льготалар юкмы икән?

З. ШӘФИКОВА,
Кәкре Атау авылы.

Әлеге сорауларга җавап эзләп редакция район социаль-тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать итте. Бүлекнең өлкән инспекторы Ф. НЕБАЙКИНА болай дип җавап бирде:

Әгәр З. Шәфикова ире вафат булганда 55 яшьтә яки аннан картрак булса аңа иренең пенсиясен күчерү мөмкин булыр иде. Шуңа бәйле рәвештә башка кайбер льготалар да алыр иде. Әмма ире үлгәндә ул әле пенсия яшенә җитмәгән, үзе эшләп йөргән кеше булгач, югарыда әйтелгән өстенлекләрдән файдалана алмый.

ЯЗ КИЛДЕ, ЯЗ!

«Алга» колхозы идарәсе, партия оешмасы, Колбай Мораса авыл Советы башкарма комитеты уллары

ДӘҮЛӘТШИН ХӘБИР КАРИП улының хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булуын тирән кайгы белән хәбәр итә һәм Дәүләтшиннар гаиләсенең авыр хәсрәтен уртаклаша.

МӨХӘРРИР Ө. У. АБДУЛЛИН.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 36. Тираж 3.350.